Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.02.2021 Менделеевск ш. № 87

Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт)
бирү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү
турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясе Беркетмәсен гамәлгә ашыру максатында 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 июнендәге 389 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2 бүлегенең 2.6 пунктындагы 1 абзацында түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр – Россия ФСХ.»;

1.2. Административ регламентның 2 бүлегенең 2.8 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.3. Административ регламентның 3 бүлегенең 3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) законнар бозган өчен салымнар, җыемнар, пеняләр һәм штрафлар түләү буенча бурыч барлыгы (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendelevsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе башлыгы Р.Р. Минебаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Абдуллин